**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

_______________　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　______

Башкарма комитет җитәкчесенең «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 2013 елның 23 сентябрендәге ПР-657 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең уртак коллегиясенең беркетмә йөкләмәсен үтәү максатларында, 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәүнең көтелгән нәтиҗәләре йомгаклары һәм 2021 елга республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2020 елның 18 декабрендәге бурычлары буенча, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Башкарма комитет җитәкчесенең 2013 елның 23 сентябрендәге ПР-657 номерлы карары белән расланган, белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү тәртибенең 2 бүлегенең 2.1 пунктын (үзг.белән 18.02.2014 №ПР-91; 28.10.2015 №ПР-116; 12.05.2016 №ПР-60; 09.03.2017 №ПР-38; 21.03.2017 №ПР-45; 04.09.2017 №ПР-144; 15.01.2018 №ПР-3;18.12.2019 №ПР-316) түбәндәге эчтәлекле «l» пунктчасы белән тулыландырырга:

«l) салым органының гаиләнең барлык әгъзаларына Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмәсе».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм районның рәсми сайтында, http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　И.И.Габдулхаев